ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 август, 2019 ел № 32/10

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары оештыру һәм уздыру Тәртибен раслау турында

2003 елның 06 нчы октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 12 маддәсе, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 13 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары оештыру һәм уздыру Тәртибен кушымтага нигезләнеп расларга.
2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
32/10 Карарына кушымта
01 август, 2019 ел

## Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары оештыру һәм уздыру Тәртибе

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип 2003 елның 06 нчы октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары оештыру һәм уздыру тәртибен (алга таба – Тәртип) билгели.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең уңайлы яшәү шартларына хокукларын үтәү максатыннан үткәрелә.

3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чиген үзгәртү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары дигәндә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү процессында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең муниципаль хокукый актлар проектлары буенча гавами фикер алышуга хокукларын гамәлгә ашыру рәвеше күздә тотыла.

### 2 бүлек. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар

4. Җәмәгать тыңлауларында 18 яшькә җиткән, даими рәвештә шәһәр территориясендә яшәүче физик затлар һәм юридик затлар, шулай ук әлеге Тәртипнең 22-24 пунктлары нигезендә җәмәгать тыңлауларында катнашучы сыйфатында теркәлгән иҗтимагый берләшмәләр катнашырга мөмкин.

### 3 бүлек. Җәмәгать тыңлауларын оештыру тәртибе

5. Халык яисә Шәһәр Советы инициативасы буенча үткәрелә торган җәмәгать тыңлаулары Шәһәр Советы тарафыннан, Яр Чаллы шәһәре Хакиме яисә Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә торган җәмәгать тыңлаулары – Яр Чаллы шәһәре Хакиме тарафыннан билгеләнә.

6. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү турында карар түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) җәмәгать тыңлаулары предметы;

2) җәмәгать тыңлаулары үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

3) җәмәгать тыңлауларында фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү өчен, җәмәгать тыңлауларында катнашуга гаризалар тапшыру өчен адрес.

7. Җәмәгать тыңлаулары үткәрү хакында карар кабул ителгән көннән башлап 10 көннән дә соңга калмыйча «Челнинские известия» газетасында бастырылырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында www.nabchelny.ru (алга таба – рәсми сайт) урнаштырылырга тиеш.

8. Җәмәгать тыңлаулары үткәрү процедурасы түбәндәге этаплардан тора:

1) җәмәгать тыңлаулары үткәрү хакында хәбәр итү;

2) рәсми сайтта җәмәгать тыңлаулары предметы буенча мәгълүмати материаллар урнаштыру;

5) җәмәгать тыңлауларында катнашучылар белән җыелыш уздыру;

6) җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү

7) җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәсе турында бәяләмә әзерләү һәм рәсми бастыру.

9. Җәмәгать тыңлаулары үткәрү хакында хәбәр түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) җәмәгать тыңлаулары предметы;

2) җәмәгать тыңлаулары үткәрү тәртибе һәм вакыты хакында мәгълүмат;

3) җәмәгать тыңлауларында катнашучылар тарафыннан җәмәгать тыңлаулары предметына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, вакыты һәм рәвеше турында мәгълүмат.

Җәмәгать тыңлаулары үткәрү турындагы хәбәрдә җәмәгать тыңлаулары предметы буенча мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат, тыңлауларда катнашучыларның җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат булырга тиеш.

10. Җәмәгать тыңлаулары уздыру турындагы хәбәр муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә, шулай ук муниципаль хокукый актларда каралган очракта, башка массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга тиеш.

11. Җәмәгать тыңлауларын әзерләү һәм үткәрү Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты белән раслана торган җәмәгать тыңлаулары үткәрү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

12. Комиссия компетенциясенә алдагы сораулар керә:

1) җәмәгатьь тыңлауларында катнашучылар составын билгеләү.;

2) чыгышлар әзерләргә кирәк булган мәсьәләләр исемлеген билгеләү.;

3) җәмәгать тыңлауларына чыгарылган мәсьәләләр буенча докладчыларның (өстәмә докладчыларның) составын билгеләү;

4) җәмәгать тыңлауларында экспертлар сыйфатында катнашырга чакырылучы вазыйфаи затлар, белгечләр, оешмалар, җәмәгатьчелек вәкилләре исемлеген билгеләү һәм аларга фикер алышуга чыгарылган мәсьәләләр буенча үз тәкъдимнәрен бирүне сорап, рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;;

5) җәмәгать тыңлаулары үткәрү регламентын билгеләү;

6) җәмәгать тыңлауларына чыгарылган муниципаль хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җыюны гамәлгә ашыру;

7) кирәкле белешмә материаллар әзерләү;

8) җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен алып баруны тәэмин итү;

9) җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләүне оештыру;

10) җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмәне бастырып чыгаруны тәэмин итү.

13. Комиссия рәисе:

1) Комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;

2) җәмәгать тыңлауларын әзерләү һәм үткәрү буенча эш планын раслый;

3) җәмәгать тыңлауларында рәислек итә;

4) әлеге нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

14. Җәмәгать тыңлаулары аларны үткәрү турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткәннән көннән башлап җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр вакыт аралыгында - бер айдан өч айга кадәр вакытта үткәрелә.

## 4 бүлек. Җәмәгать тыңлауларында каралучы проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү

15. Җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектны һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштыру чорында физик һәм юридик затлар, иҗтимагый оешмалар Комиссия адресына карала торган проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

16. Тәртипнең 15 пункты нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җәмәгать тыңлаулары предметына туры килергә тиеш. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җәмәгать тыңлаулары предметына туры килмәгән очракта, Комиссия мондый тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне җәмәгать тыңлаулары беркетмәсенә кертми.

17. Тәртипнең 15 пункты нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, җәмәгать тыңлауларында катнашучы тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр бирү факты ачыкланган очракта, каралмыйлар

18. Тәртипнең 15 пункты нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, Тәртипнең 17 пунктында каралган очрактан тыщ. теркәлергә һәм Комиссия тарафыннан каралырга тиеш,

19. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар идентификацияләү максатында үзләре турында белешмәләр (мондый белешмәләрне раслаучы документлар белән бергә) тапшыралар:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, яшәү (теркәлү) урыны - физик затлар өчен;

2) исеме, төп дәүләт теркәве саны, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен.

20. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның шәхси мәгълүматларын эшкәртү 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ санлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## 5 бүлек. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү

21. Җәмәгать тыңлаулары җыелыш формасында үткәрелә.

22. Җыелыш башланыр алдыннан Комиссия җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны терки. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү махсус журналда башкарыла.

23. Физик затларны теркәү шәхесне раслаучы документ, шулай ук яшәү урынын раслаучы документ нигезендә башкарыла. Паспортта күрсәтелгән даими теркәлү адресы белән туры килмәгән адрес буенча теркәлгән очракта, физик зат тору урыны буенча теркәлү турында таныклык күрсәтә.

24. Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне теркәү нигезләре:

1) юридик затны, шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәләре;

2) юридик зат яисә шәхси эшмәкәр вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;

3) юридик зат яисә шәхси эшмәкәр вәкиленең шәхесен раслаучы документ.

25. Теркәүдән баш тарту түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

1) әгәр дә зат теркәлгәндә Тәртипнең 23, 24 пунктларында каралган документларны тапшырмаса;

2) әгәр дә зат Тәртипнең 23, 24 пунктларында каралган документларны тапшырганда дөрес булмаган белешмәләр бирсә;

3) Тәртип таләпләре нигезендә җәмәгать тыңлауларында катнашучы булмаса.

26. Теркәлү узмаган затларга җыелышта катнашу рөхсәт ителми.

27. Алкоголь, наркотик яки агулы матдәләр кулланып, исерек хәлдә булган затларга җыелышта катнашырга рөхсәт ителми.

28. Җыелышта чыгыш ясарга теләүче җәмәгать тыңлауларында катнашучылар Тәртипнең 22 пунктында күрсәтелгән тәртиптә теркәлү журналында чыгыш ясаучылар буларак теркәлергә тиеш.

29. Җыелыш башланыр алдыннан Комиссия рәисе хәбәр итә:

1) җәмәгать тыңлауларында фикер алышырга тиешле проектны;

2) җәмәгать тыңлауларын үткәрү тәртибен һәм эзлеклелеген;

3) чакырылган затлар составы, җәмәгать тыңлауларында катнашучылар саны турында мәгълүматны;

4) докладчыларны, җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга чыгыш ясауга бирелгән вакытны;

5) җәмәгать тыңлауларында карала торган проект буенча кергән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр булуын;

6) җәмәгать тыңлаулары уздыру өчен кирәкле башка мәгълүматны.

30. Комиссия рәисе фикер алышуга тәкъдим ителгән проект буенча докладчыларга сүз бирә, докладлардан соң җәмәгать тыңлауларында катнашучылар сораулар бирә. Сораулар телдән дә, язмача да бирелергә мөмкин.

Комиссия рәисе, Тәртипнең 28 пункты нигезендә чыгыш ясаучылар сыйфатында теркәлгән җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга чират тәртибендә сүз бирә

Комиссия рәисе чираттан тыш чыгыш ясау хокукына ия.

Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар бары тик Комиссия рәисе рөхсәте белән генә чыгыш ясыйлар

31. Чыгыш ясаучылар үз чыгышында башка затларның намусына һәм абруена зыян китерүче тупас, мәсхәрәле гыйбарәләр кулланырга, законсыз гамәлләргә өндәргә, белә торып ялган мәгълүмат таратырга, кемнең дә булса адресына нигезсез гаепләүләр белдерергә хокуклы түгел.

Җыелышта чыгышлар җәмәгать тыңлауларының предметы белән бәйле булырга тиеш.

Җыелышта аудиоязма алып барыла.

32. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелыш үткәрүгә комачауларга, чыгышларны кычкырып яйсә алкышлар белән бүлдерергә хокуклы түгел.

33. Тәртипнең 30, 31 пунктларында билгеләнгән тәртипне сакламаганда, җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелыш уздыру урыныннан чыгарылырга мөмкин.

34. Җыелыш беркетмәсенә Комиссия рәисе кул куя.

35 Җыелыш эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 12:00 сәгатькә кадәр һәм 13:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр үткәрелә.

Җыелышны эш көне булмаган бәйрәм көненә, эш көне булмаган бәйрәм көне алдыннан, шулай ук эш көне булмаган бәйрәм көненнән соң килүче көнгә билгеләү рөхсәт ителми.

36. Комиссия җыелышта катнашучыларга яисә аларның вәкилләренә бинага керү мөмкинлеген чикләргә хокуклы түгел.

Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелышы тикшерелә торган проектларны күрсәтү, аудиоязма алып бару өчен һәм чыгыш ясау өчен махсус җиһазландырылган, шулай ук инвалидлар һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән халык төркеме өчен уңайлы бинада

үткәрелә. Бина җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны сыйдырырлык зурлыкта булырга тиеш.

### 6 бүлек. Җәмәгать тыңлаулары беркетмәсе

37. Комиссия җәмәгать тыңлауларының беркетмәсен әзерли һәм рәсмиләштерә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен рәсмиләштерү датасы;

2) җәмәгать тыңлауларының башлануы турында бастырып чыгарылган хәбәрдәге мәгълүмат, аны бастырып чыгару чыганагы һәм бастыру датасы;

3) җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның тәкъдимнәре һәм искәрмәләрен кабул итү вакыты һәм җәмәгать тыңлаулары уздырылучы территория турында мәгълүмат,

4) җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен, җәмәгать тыңлаулары үткәрелә торган территориядә даими яшәүче җәмәгать тыңлауларында катнашучы гражданнарның тәкъдимнәре һәм искәрмәләре аерым күрсәтелә.

38 Җәмәгать тыңлаулары беркетмәсесенә тыңлауларда проектны карауда катнашучылар исемлеге теркәлә, анда катнашучылар турында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, яшәү (теркәлү) урыны – физик затлар өчен;

2) исеме, төп дәүләт теркәве саны, урнашу урыны һәм адресы – юридик затлар өчен.

39. Җәмәгать тыңлаулары беркетмәсе җәмәгать тыңлаулары тәмамлан вакыттан башлап биш эш көнендә әзерләнә.

### 7 бүлек. Җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәсе турында бәяләмә

40 Җәмәгать тыңлаулары беркетмәсенә нигезләнеп Комиссия җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәсе турында бәяләмә әзерли.

Җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәсе турында бәяләмә җәмәгать тыңлаулары тәмамланганнан вакыттан алып җиде эш көне эчендә әзерләнә .

41. Җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәсе турында бәяләмәдә күрсәтелергә тиеш:

1) җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәсе турында бәяләмәне рәсмиләштерү датасы;

2) җәмәгать тыңлауларында каралган проектның исеме, җәмәгать тыңлауларында катнашучылар саны турында мәгълүмат;

3) җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәсе турында бәяләмә әзерләүгә нигез булган җәмәгать тыңлаулары беркетмәсе реквизитлары;

4) җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның тәкъдимнәре һәм искәрмәләренең эчтәлеге, җәмәгать тыңлаулары үткәрелә торган территориядә даими яшәүче җәмәгать тыңлауларында катнашучы

гражданнарның тәкъдимнәре һәм искәрмәләре аерым күрсәтелә. Җәмәгать тыңлауларында берничә катнашучы тарафыннан бер үк төрле тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелгән очракта, мондый тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерү рөхсәт ителә;

5) җәмәгать тыңлауларында катнашучылар тарафыннан кертелгән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне исәпкә алуның максатка ярашлы яисә максатка ярашсызлыгы турында Комиссиянең дәлилләнгән рекомендацияләре, җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре.

42. Җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәсе турында бәяләмә кул куелган көннән алып җиде көннән дә соңга калмыйча «Челнинские известия» газетасында һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында бастырылырга тиеш.

43. Җәмәгать тыңлаулары материаллары рәсми документларны саклау өчен Россия законнары белән билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитетта сакланырга тиеш.